*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 35**

**1. Халык әкиятләре турында исеңә төшер. Татар халык әкиятләренең төп үзенчәлекләрен барлап яз. Мисаллар китер. (6 балл)**

**2. Рәсемгә игътибар ит. Ул кайсы әсәргә карата ясалган? Әсәрнең исемен, авторын атап, аның кемнәр турында булуын яз. (5 балл)**



**3. «Мокамай» поэмасының авторын билгелә. (1 балл)**

а) Гаяз Исхакый

ә) Гомәр Бәширов

б) Галимҗан Ибраһимов

в) Һади Такташ


**4. Шигырьнең исемен, авторын яз. Шигырьне тулысы белән искә төшереп, анда бирелгән хис-кичерешләрне билгелә. (7 балл)**

Һәр көн юлдан дистәләгән
Юлчы уза, тузан туза.
Һәм һәр юлчы - моңлы җырчы –
Имән җырын тыңлап уза.

Җилле көнне юлчыларны
Имән саклый җил-яңгырдан.
Җылы биреп җил-су үтмәс
Яшел чуклы юрганыннан.

Күләгәсе ял иттерә
Кырда эшләп арганнарны,
Кавыштыра айлы кичтә
Яшерен утта янганнарны.

**5. Портретка игътибар ит. Биредә кем сурәтләнгән? Бу әдип турында өч фактны искә төшереп яз. (6 балл)**



1) ____________________________
2) ____________________________
3) ____________________________

**6. Яхшылык ит тә мәңгегә оныт, диләр. Ничек уйлыйсың, бу дөресме? Бу турыда фикерләреңне яз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытма. (10 балл)**